**Казан шәһәр Думасының 2024 елның 28 августындагы**
**3-32 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 46 статьясындагы 1 пунктының 1.2 пунктчасы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 1565 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә махсус билгеләнештәге яшелләндерү ярдәмче зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәр Думасы карары проектын әзерләү хакында» карарын исәпкә алып, Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең 2022 елның 26 августындагы 290-13364 номерлы «Әлмәт – Түбән Новгород» магистраль нефть продуктлары үткәргеченнән торба өлешен бетерү турындагы хаты, Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенең 2024 елның 25 июлендәге бәяләмәсе һәм 2024 елның 30 маеннан 2024 елның 20 июненә кадәр уздырылган иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләре нигезендә Казан шәһәр Думасы **карар чыгарды:**

1. Казан шәһәр Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында: әлеге карар кушымтасына туры китереп, территориаль зоналарның махсус билгеләнештәге (ОСН) яшелләндерү зонасы – җитештерү-коммуналь объектларның мохиткә тискәре йогынтысы аз булган зонасы (П2) (38 номерлы контур), рекреацион зона (Р2) (217 номерлы, 215 номерлы контур), индивидуаль һәм блоктан торак төзелеше зонасы (Ж1) (155 номерлы контур, 150 номерлы контур, 194 номерлы контур, 120 номерлы контур, 79 номерлы контур), махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы (ПР) (23 номерлы контур, 18 номерлы контур), территориядән фактта файдалану зонасы (Ф) (35 номерлы контур, 42 номерлы контур, 41 номерлы контур),


катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (82 номерлы контур), табигый территорияләр зонасы (Р1) (89 номерлы контур, 47 номерлы контур), табигатьне саклау, рекреация һәм башка кыйммәтле әһәмияттәге махсус зона (Р0) (25 номерлы контур), махсус билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (С3) (37 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru).

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәр Думасының 2024
елның 28 августындагы 3-32
номерлы карарына кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре чагылдырылган шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**Р1 - 89**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зоналар**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төре исеме** |
|---|---|---|
| | Ж1 | Индивидуаль һәм блоктан торак төзелеше зонасы |
| | П2 | Мохиткә аз гына тискәре йогынты ясаучы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы |
| | ПР | Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы |
| | Р2 | Рекреация зонасы |
| | Р0 | Табигатьне саклау, рекреация һәм башка кыйммәтле әһәмияттәге махсус зона |
| | СЗ | Махсус билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | Ф | Территориядән фактта файдалану зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | Р1 | Табигый территорияләр зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре чагылдырылган шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**